# КАРАР

**23 ноябрь, 2020 ел** **№1**

**Кукмара муниципаль районы Важашуравыл җирлегенең Починок Сутер авылында поселогында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2020 елның 23 ноябрендә түбәндәге мәсьәлә буенча үткәрелгән гражданнар җыены нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенының беркетмәсе төзелде:

« Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга: «Көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлар, гомуми белем бирү мәктәпләрендә укучылар, I төркем инвалидлары, 80 яшьтәге һәм аннан өлкәнрәк яшьтәге пенсионерлардан кала, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Важашур авыл җирлегенең Починок Сутер авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр яшәүчедән 2021 елда үзара салымны 500 сум күләмендә кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен юнәлтүгә сез ризамы:

- Починок Сутер авылының Ленин, Бакча, Яшьләр, Яңа урамнарында вак таш түшәп, юллар төзү һәм төзекләндерү, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру;
- Починок Сутер авылында юлларны җәен һәм кышын карап тоту һәм чистарту (ГСМ алу);
- Починок Сутер авылында урам яктырткычларын төзекләндерү һәм сатып алу;
- Починок Сутер авылына тышкы видеокүзәтү камералары сатып алу һәм урнаштыру?»

«РИЗА» «КАРШЫ»

Гражданнар җыены беркетмәсе нигезендә:

2020 елның 23 ноябренә торак пунктта яшәүче гражданнарның гомуми саны – 202 кеше.

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 202 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 121 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Риза» позициясе өчен җыенда катнашкан 121 кеше тавыш бирде;

«Каршы» позициясе өчен җыенда катнашкан 0 кеше тавыш бирде;

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Важашуравыл җирлегенең Починок Сутеравылындагы халык җыенын узган дип, гражданнар җыенының нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.
2. Түбәндәге мәсьәлә буенча карарны: « Көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлар, гомуми белем бирү мәктәпләрендә укучылар, I төркем инвалидлары, 80 яшьтәге һәм аннан өлкәнрәк яшьтәге пенсионерлардан кала, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Важашур авыл җирлегенең Починок Сутер авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр яшәүчедән 2021 елда үзара салымны 500 сум күләмендә кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен юнәлтүгә сез ризамы:

- Починок Сутер авылының Ленин, Бакча, Яшьләр, Яңа урамнарында вак таш түшәп, юллар төзү һәм төзекләндерү, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру;
- Починок Сутер авылында юлларны җәен һәм кышын карап тоту һәм чистарту (ГСМ алу);
- Починок Сутер авылында урам яктырткычларын төзекләндерү һәм сатып алу;
- Починок Сутер авылына тышкы видеокүзәтү камералары сатып алу һәм урнаштыру?»

«РИЗА» «КАРШЫ»

кабул ителгән дип танырга.

3. Җыенның нәтиҗәләрен мәгълүмат стендларында, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында www.pravo.tatarstan.ru адресы буенча бастырып чыгарырга.
4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Важашур
авыл җирлеге башлыгы П.Л.Иванов